**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 113 21 сентябрь 2018 ел

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Урсай авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Урсай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициациясе турында” Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 03 сентябрендәге 12 номерлы карары нигезендә

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Урсай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:
"2019 елда үзара салым кертүгә Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Җәлил урамындагы Урсай авылында (тыкрыкта), - Гастелло урамында, Мөслим авылында - Такташ урамында юлларга вак таш түшәү;
2) Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- Урсай авылы һәм Мөслим авылы зиратларын карап тоту (үләннәрне чаптыру, агачларны кисү, куакларны кисү);
3) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Урсай авылы һәм Мөслим авылы суүткәргеч линияләрен ремонтлау;
- Урсай авылы һәм Мөслим авылы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

4) Җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректле керүен тәэмин итү дә керә:
- Мөслим авылы паркын карап тоту (чүп үләннәрен чаптыру, агачлар, куаклар утырту, эскәмияләрне буяу);
- Урсай авылындагы Сабантуй бәйрәмен уздыру мәйданында киртәләр урнаштыру;
5) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, җирлек территориясен төзекләндерүне әлеге кагыйдәләр нигезендә оештыру:
- Урсай авылында, Мөслим авылында юлларны кардан чистарту
- Урсай авылы җирлегендә һәм Мөслим авылындагы урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм аларны алыштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү)
- җирлек территориясендә чүп үләннәрен чаптыру хезмәте

6) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- Урсай авылында һәм Мөслим авылында («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкән кешеләр көне», «Яңа ел», «Халыкара хатын-кызлар көне - 8 март», «23 февраль - Ватанны саклаучылар көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис: И.А.Абдуллин